Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен тапшыру турында

Килешү

Кукмара ш. " 23" май 2023 ел

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Башлыгы исеменнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, бер яктан, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставы нигезендә эш итүче Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгы исеменнән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучы, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. Килешү предметы

Әлеге Килешүнең предметы булып җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен район җирле үзидарә органнары тарафыннан җирлекнең җирле үзидарә органнарына тапшыру тора:

муниципаль торак фондын исәпкә алу;

Гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыны бирү максатларында гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү;

социаль файдалану торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану максатларында ггражданнарның һәм алар белән даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемнәрен һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтенең хакын билгеләү;

социаль файдалану торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гражданнарның һәм алар белән даими яшәүче гаилә әгъзаларының керемнәрен һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтенең максималь күләмен билгеләү;

билгеләнгән тәртиптә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алуны алып бару;

социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алырга;

аз керемле гражданнарга муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча билгеләнгән тәртиптә торак урыннары бирү;

муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибен билгеләү;

муниципаль торак фондында булган хезмәт торагын наем шартнамәсе буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә алу;

гражданнарга муниципаль торак фондында хезмәт урыны буенча торак наемы шартнамәләре буенча торак урыннары бирү;

махсуслаштырылган торак фонды составына торак биналарны кертү һәм төшереп калдыру;

социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру буенча документларны рәсмиләштерү.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Районның җирле үзидарә органнары җирлекнең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә тиеш:

әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне (алга таба – вәкаләтләр) гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чараларын;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны.

2.2. Районның җирле үзидарә органнары җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең үтәлешен, шулай ук әлеге Килешүнең 4.1 – 4.3 пунктларында билгеләнгән тәртиптә бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны контрольдә тоту хокукына ия;

авыл җирлеге җирле үзидарә органнарыннан әлеге Килешү предметына кагылышлы мәгълүмат алырга.

2.3. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә бурычлы:

законнар таләпләре нигезендә вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга, шул исәптән район җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән финанс чараларыннан бары тик вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен генә максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

районның җирле үзидарә органнарына вәкаләтләрнең үтәлеше турында квартал саен хисап тапшырырга, шулай ук аерым соратулар буенча Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат бирергә;

2.4. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен районның җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм кулланырга;

район җирле үзидарә органнарыннан вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, өстәмә рәвештә законнар нигезендә башка матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдаланырга.

## 3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен, финанс чаралары бирү тәртибе

3.1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле финанс чаралары бюджет законнары нигезендә бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә.

3.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары күләме

... елга сум.

3.3. Җирлекнең җирле үзидарә органнары тарафыннан финанс чаралары максатсыз файдаланылган очракта, алар район җирле үзидарә органнары таләбе буенча ун көнлек срокта район бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

## 4. Вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерү

4.1. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра, җирлек башкарма комитетыннан бирелгән финанс чараларыннан файдалану турында кирәкле мәгълүматны һәм әлеге Килешүнең кушымтасы нигезендә хисап соратып ала.

4.2. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты соратуы буенча авыл җирлеге башкарма комитеты соратып алына торган мәгълүматны бирергә бурычлы һәм, хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, әлеге Килешүгә кушымта нигезендә квартал хисапларын төзи һәм тапшыра.

4.3. Бирелгән финанс чараларын тотуны тикшерү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Контроль-хисап палатасы тарафыннан, шул исәптән Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты соратуы буенча башкарыла.

## 5. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

5.1. Килешү басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

5.2. Әлеге Килешүнең 5.1 пунктында каралган срок тәмамланганчы 30 көннән дә соңга калмыйча аны өзү турында Якларның берсе дә гариза бирмәсә, Килешү 2025 елга озайтылган дип санала.

## 6. Килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре һәм тәртибе

6.1. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда түбәндәгечә туктатылырга мөмкин:

Яклар килешүе буенча;

Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, берьяклы тәртиптә.

6.2. Әлеге Килешүнең өзелүе турында хәбәрнамә икенче Якка аның фаразланган гамәлдә булу вакыты тәмамланганчы 30 көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә җибәрелә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы срогыннан алда туктатылган очракта, җирлекнең җирле үзидарә органнары, вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән файдаланылмаган финанс чараларын районның җирле үзидарә органнарына кире кайтаралар.

## 7. Якларның җаваплылыгы

7.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык барлыкка килүгә нигез булырга мөмкин.

7.2. Әлеге Килешү буенча Якларның берсе йөкләмәләрен үтәмәгән өчен,

гаепле Як икенче Якка әлеге Килешүнең 3.2 пунктында каралган финанс чаралары күләменең 0,1 проценты күләмендә штраф түли.

7.3. Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне алга таба үтәүдән азат итми.

## 8 статья. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

8.1. Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә.

8.2. Бәхәсне сөйләшүләр яки килештерү процедураларын үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.

## 9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Килешүгә якларның үзара ризалыгы белән кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9.2. Килешү тигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә һәр Як өчен берәр төзелде.

## 10. Якларның имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге башлыгы |
| __________ А.Х. Гарифуллин | ___________ Ф.М.Фаттахов |